**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЙДАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**өченче чакырылыш илле алтынчы утырыш**

# КАРАРЫ

**2019 ел «19» июнь № 134 Айдар авылы**

Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге Советының «Җирләү эше һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге территориясендәге муниципаль зиратларны тоту кагыйдәләре турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары турында»гы 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы 2019 елның 21 маендагы 415 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1.Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге Советының «Җирләү эше һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге территориясендәге муниципаль зиратларны тоту кагыйдәләре турында»гы карарына (15.12.2016 нчы елның №49, 19.09.2018 нче елның №102 номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә :
1) Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге территориясендә җирләү эшен оештыру тәртибенә:
А) «9. Җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге»бүлегенә:
- 3 пунктнытүбәндәге тәртиптә бирергә:
«3. Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе, Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты белән килешү буенча җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә
2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль районы Айдар
авыл җирлеге башлыгы урынбасары А.Г. Фаляхова